КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 май г.Казань № 490

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 ноябрь, 1105 нче карары белән расланган Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 ноябрь, 1105 нче карары белән расланган Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек

субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка «Министрлык» сүзеннән соң «квартал саен» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның бишенче абзацында «нәтиҗәләрен» сүзен «нәтиҗәсен» сүзенә алмаштырырга;

16 пунктта:

дүртенче абзацта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәсе» сүзенә алмаштырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) Министрлык тарафыннан аларга карата субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия алганда);»;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия бирү нәтиҗәсе – «үстерү» чаралары кысаларында үсешнең индивидуаль карталары эшләнгән һәм расланган кимендә 10 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы:

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгәндә – субсидия бирелә торган кварталның соңгы көненнән дә соңга калмыйча;

чыгымнарны каплауга субсидия бирелгәндә – килешүгә кул куелган датадан соң килә торган җиденче эш көненнән соңга калмыйча.»;

19 пунктта:

өченче абзацта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәсе» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «хисап кварталыннан соң килә торган» сүзләрен «килешүгә кул куелган датадан соң килә торган» сүзләренә, «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәсе» сүзенә алмаштырырга;

21 пунктта:

дүртенче абзацта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәсе» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәсе» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы – унөченче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

$$«A = \left(1 - \frac{d}{D}\right) \times X \times V,$$

монда:

d – килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелгән күрсәткече;

D – килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече;

X – хисап кварталының соңгы көне хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкының төп ставкасына тигез булган төзәтү коэффициенты;

V – субсидия алучы тарафыннан алынган субсидия акчасы күләме.»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.».

2. Тәртипнең 5 пунктындагы өченче абзацы гамәлен 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы утыз өченче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин